**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 17 гыйнварындагы 41 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2021 елның 29 декабрендәге 3515 номерлы**
**«Казан шәһәрендә гомуми белем бирү программаларын**
**гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларына**
**алу турында гаризалар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең**
**административ регламентын раслау хакында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында»гы федераль законның 24 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Казан шәһәрендә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган мәгариф учреждениеләренә чираттан тыш, беренче чиратта һәм өстенлекле тәртиптә кабул итү хокукына ия булган балалар категорияләрен аныклау максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 29 декабрендәге 3515 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларына алу турында гаризалар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Әлеге Регламентның йогынтысы гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган типлаштырылмаган муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагылмый»;

1.2. 1.2.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.2.1.1. укырга чираттан тыш кабул итү хокукына түбәндәгеләр ия:

1.2.1.1.1. интернаты булган Оешмаларга:

- 2010 елның 28 декабрендәге 403-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе

Тикшерү комитеты турында»гы федераль законның 35 статьясындагы 25 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Тикшерү комитеты хезмәткәрләренең балалары;

- 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында»гы Россия Федерациясе законының 19 статьясындагы 3 пункты нигезендә судья балалары;

- 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы «Россия Федерациясе прокуратурасы турында»гы федераль законның 44 статьясындагы 5 пункты нигезендә Россия Федерациясе прокурорлары балалары;

1.2.1.1.2. Оешмаларга – 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында»гы федераль законның 24 статьясындагы 8 пунктында күрсәтелгән балалар һәм 2016 елның 3 июлендәге 226-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре турында»гы федераль законның $28^{1}$ статьясында күрсәтелгән балалар гаиләләренең яшәү урыны буенча».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**